| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ**<br>**14.02.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 169** |

Татарстан Республикасы "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлекнең 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы вәкиллекле органы карары белән расланган муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында», 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә дәүләти-шәхси партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законнары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында", 2016 елның 29 сентябрендәге 75-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 15, 99-101 статьялары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлекнең 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы вәкиллекле органы карары белән расланган муниципаль берәмлеге Уставына (2006 елның 31 октябрендәге 96 номерлы, 2007 елның 09 июлендәге 190 номерлы, 2008 елның 10 июнендәге 313 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге 378 номерлы, 2010 елның 16 июнендәге 524 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 134 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге 223 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 361 номерлы, 2015 елның 05 мартындагы 492 номерлы, 2015 елның 28 августындагы 561 номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 61 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 99 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 7.1 статьяда:

1.1) 7.1 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.»;

2) 39 статьяда:

2.1) 39 статьяның 17 пунктын 18 пункт итеп санарга, 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“17) муниципаль- шәхси партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында муниципаль-шәхси партнерлык өлкәсендә карарлар кабул итә, әгәр гавами партнер-муниципаль берәмлек булса, йә муниципаль берәмлек катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла икән (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла торган очрактан тыш), шулай ук 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Дәүләт-шәхси партнерлык, Россия Федерациясендә муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, район Уставында һәм Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актларында каралган;

17.1) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт-шәхси партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вәкиле җирле үзидарә органы билгели;

17.2) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт – шәхси партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясындагы 2-5 өлешләре нигезендә проектның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына муниципаль-шәхси партнерлык проектын җибәрә;

3) 44 статьяда:

3.1) 44 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын 10 пункт итеп санарга, 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә:

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итә;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координация органнары булдыра;

-хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрә;

-муниципаль берәмлек территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

- 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1, 7-10 пунктларында каралган хокук бозуларны хокук бозуларның профилактик йогынтының формаларында профилактикалауны гамәлгә ашыра;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка хокукларны гамәлгә ашыра;”;

4) 44.2 статьяда:

4.1) 44.2 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын 10 пункт итеп санарга, 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә:

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итәләр;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координация органнары булдыралар;

- хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрәләр;

-муниципаль берәмлек территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәләр;

- 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1, 7-10 пунктларында каралган хокук бозуларны хокук бозуларның профилактик йогынтының формаларында профилактикалауны гамәлгә ашыра;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка хокукларны гамәлгә ашыралар;”;

2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвеннән соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 101 статьясындагы 2,3 өлешләре нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**